**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы № 67 «11» сентябрь 2017 ел

Референдум үткәрүне инициацияләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, “Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль Үчәлле авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә,

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум уздыру инициативасы белән чыгарга:

"Сез Үчәлле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге өчен;
2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру өчен (урамнарны яктыртуны, территорияне яшелләндерүне, урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр куюны да кертеп);
3) җирлек торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү өчен;
4) җирлектә балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыруга;
5) ритуаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту өчен;
6) җирлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру өчен

«РИЗА» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны:

- адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында:
Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет ур., 51 йорт;
Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Якты Күл авылы, Якты Күл ур., 26 йорт;
Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Текмәле авылы, Ишкәев ур., 15 йорт;
Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Кызыл Йолдыз авылы, Кызыл Йолдыз ур., 2 нче йорт
- түбәндәге веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы: http://pravo.tatarstan.ru
- Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында түбәндәге веб-адрес буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru.урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Рәис Г.М.Тухвәтуллина